Зурлар төркемендә Г. Тукайның 133 еллыгына багышланган “Тукай эзләреннән” исемле күргәзмә оештырыла. Биредә балалар һәм аларның ата-аналары тарафыннан ясалган кул эшләре, рәсемнәр урын алган.

Безнең балалар бакчабызда татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның 133 еллыгына багышланган кичә узды. Балаларны Тукайның шигырьләре һәм әкиятләре белән таныштырдык. Зурлар төркеме балалары бәйрәмгә бик зур кызыксыну белән әзерләнде. Әти-әниләре белән өйләрендә Тукай әсәрләренә багышланган кул эшләре, рәсемнәр ясап алып килделәр. Балалар үзләре ясаган рәсемнәрен күргәзмәдә күреп бик сөенде.

Бәйрәм чарасы бик матур башланды. Балалар "Бәйрәм бүген" көенә залга керделәр һәм "Туган тел" җырын бик матур һәм моңлы итеп башкардылар. Әкият геройлары - Су анасы, Шүрәле бәйрәмгә килде. Балалар аларны күреп бик нык гаҗәпләнде.

Габдулла Тукайның "Бала белән күбәләк", "Гали белән кәҗә", "Кызыклы шәкерт", "Безнең гаилә" һәм башка шигырьләрен, шулай ук Тукайга багышланган шигырьне сөйләделәр.

Зурлар төркеменә йөрүче балалар татар халык уены  "Ачык авыз" уенын уйнадылар. Шүрәле үзенең кызыклы сорауларын бирде. Балалар да сынатмады, алар сорауларга бик дөрес җавап бирделәр.

Кичә ахырында алып баручы балаларны яшь тукайчылар дип атады. Чыннан да, алар газиз Тукаебыз теленә тугрылыклы, мирасыбызны саклаучылар. Туган илебезнең бөек уллары һәм кызлары булып үссеннәр иде балаларыбыз.




1941
1945






РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ
УЧРЕЖДЕНИЕ КУЛЬТУРЫ
БУГУЛЬМИНСКИЙ
КРАЕВЕДЧЕСКИЙ
МУЗЕЙ



